КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 ноябрь г.Казань № 1421

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 ел, 18 февраль, 153 нче карары белән расланган Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 ел, 18 февраль, 153 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 июль, 859 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 ноябрь, 1421 нче карары редакциясендә)

Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары
исемлеге

1. Бер ел дәвамында закон көченә кергән мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) бозган өчен юридик затка, индивидуаль эшмәкәргә яки аларның вазыйфаи затларына административ җәза билгеләү турында биш һәм аннан күбрәк карар булу:

а) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән – аттракционнарның техник торышына һәм аларны эксплуатацияләүгә карата;

б) Евразия икътисадый берлеге Советының «Аттракционнар куркынычсызлыгы турында» Евразия икътисадый берлегенең техник регламенты хакында» 2016 елның 18 октябрендәге 114 номерлы карары белән кабул ителгән «Аттракционнар куркынычсызлыгы турында» Евразия икътисадый берлегенең техник регламентында билгеләнгән – аттракционнарның куркынычсызлыгына карата;

2. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәдә билгеләнгән срокта мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү буенча чаралар күрү турында хәбәрнамәне тапшырмау.

3. «Гостехнадзор Эксперт» дәүләт мәгълүмат системасындагы мәгълүмат буенча календарь ел дәвамында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аттракционнарны дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1939 номерлы карары белән расланган Аттракционнарны дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләренең 29 пунктындагы «а» – «г» пунктчаларында күрсәтелгән нигезләрнең берсе буенча дәүләт теркәвенә алу туктатылган контрольдә тотылучы зат аттракционнары санынннан аттракционнар санын 20 һәм аннан күбрәк процентка арттыру.

4. Календарь ел дәвамында гражданнардан, оешмалардан аттракционнарны эксплуатацияләү өлкәсендә контрольдә тотылучы зат тарафыннан ял һәм күңел ачуны оештыру хезмәтләрен күрсәтү сыйфаты тиешенчә булмау турында кергән ике һәм аннан күбрәк белешмә булу.

---